**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.09.2024 № 1002

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Нурлат муниципаль районы җитәкчеләр составына, Гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнарга һәм халыкка хәбәр итүне оештыру турында" 2008 елның 21 гыйнварындагы 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2008 елның 21 гыйнварындагы 29 номерлы карары белән расланган җитәкче составка, Гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнарга һәм халыкка хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Террактлар куркынычы янаган очракларда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең төп ысулы булып «Халыкка хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәте турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы карары таләпләре нигезендә ведомстводан һәм милек рәвешеннән бәйсез рәвештә чыбыклы тапшырулар, радиотапшырулар һәм телевидение челтәрләреннән файдаланып сөйләм мәгълүматын тапшыру тора».».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин